## СҮЗЛЕКНЕҢ ТӨЗЕЛЕШЕ

1. Сүзлектә баш сүзләр – вокабулалар – алфавит тәртибендә урнаштырылды һәм алар, үзләренә караган материал белән бергә, сүзлек мәкаләсен тәшкил итә. Ул түбәндәге өлешләрдән тора:

1) баш сүз;
2) баш сүзнең русчага тәрҗемәсе;
3) баш сүзгә аңлатма;
4) иллюстратив мисал.

2. Сүзлектә баш сүзләр калын баш хәрефләрдән алфавит тәртибендә урнаштырылды.

**АЛМАГАЧЛЫК** ЯБЛОННИК. Алмагачлар үскән урын, алма бакчасы. *Инде картая башлаган алмагачлыкны үзенеке итеп тою кыз белән егетнең соңгы сөйләшүеннән соң туды (Р. Сибат).*

**АЛМАЛЫК** *к.* **алмагачлык**. *Яр буйларында ук үсеп утырган агачлар арасыннан кереп китәсең дә баланлыкларга, --- алмалыкларга барып чыгасың (Р. Рахман).*

3. Компонентлары аерым язылган, лексик берәмлек тәшкил иткән кушма сүзләр дә аерым сүзлек мәкаләсе итеп китерелде.

**САРЫМСАК ҮЛӘНЕ** ЧЕСНОЧНИК, ЧЕСНОЧНИЦА. Әвернәчәчәклеләр семьялыгыннан ак чәчәкле, орлыклары кузак эчендә булган, тәмләткеч итеп кулланыла торган икееллык үләнчел үсемлек.

**ДАРУЛЫК ЯУШАН** ВЕРОНИКА ЛЕКАРСТВЕННАЯ. Сыраҗчалар семьялыгыннан түшәлмә сабаклы, каршыдаш яфраклы, ачык зәңгәр, аксыл яки алсу чәчәкле күпьеллык үләнчел үсемлек. *Дарулык яушан ешрак вак куаклар арасында, --- урман кырыйларында, --- ярлы туфракларда үсә (Е. Солодухин).*

4. Баш сүз янәшәсенә шулай ук якты баш хәрефләрдән аның рус теленә тәрҗемәсе урнаштырылды. Шуннан соң сүзгә аңлатма бирелде, аерым очракларда ул иллюстратив материал белән ныгытылды.

**БӘБРИЯ** РОЗМАРИН. Иренчәчәклеләр семьялыгыннан чәнечкеле яфраклы, зәңгәрсу шәмәхә чәчәкле мәңге яшел куак; шул куакның аштәмләткеч буларак куллану өчен киптерелгән яфрагы. *Шуннан соң тавыкны тирән эчле кәстрүлгә урнаштырып, --- бәбрия сабакларын салырга, --- салмак кына утта пешерергә кирәк (Татар ашлары).*

**СЫРГАНАК** ОБЛЕПИХА. Сырганакчалар семьялыгыннан чәнечкеле ботаклы, көмешсыман яфраклы, ботакларына сарылып үскән кызгылт сары, әчкелтем, сусыл каты төшле җимешле куак яки агач; шул үсемлекнең җимеше. *Монда виноград, --- сырганак, гөлҗимеш агачлары да шау җимештә утыра (Сөембикә).*

5. Атаманың әдәби һәм диалекталь вариантын билгеләү күп очракта бәхәс тудыра, шуңа күрә әдәби дип саналган, тиңдәшләренә караганда күбрәк кулланыла торган сүз төп атама итеп бирелде. Аңлатмадан соң өтер аша атаманың синонимнары китерелде. Атаманың диалекталь вариантта кулланылуы анык билгеле очракларда гына баш сүз янәшәсенә *диал.* билгесе куелды:

**МӘШКӘ** *диал. к.* **гөмбә.**

**ЙОНЛЫ ҖИМЕШ** *диал. к.* **крыжовник.**

**МЕҢЬЯФРАК** ТЫСЯЧЕЛИСТНИК. Оешмачәчәклеләр семьялыгыннан тар каурыйсыман телгәләнгән вак яфраклы, калкансыман оешкан аксыл чәчәкле, хуш исле күпьеллык үләнчел үсемлек; ак мәтрүшкә, очык печәне, пәри акбашы, тиле акбаш, ярмабаш. *Әгәр кырларда меңьяфрак дигән үлән яхшы уңса, кыш йомшак булыр (Х. Мәхмүтов).*

6. Аңлатма фәкать төп атамага бирелеп, синонимнары шул сүзгә юнәлтелде (*к.*).

**БАШАКЛЫ КУЛЬТУРАЛАР** *күпл. к.* **башаклылар**. --- *элек яшел конвейер өчен тотылган 150 гектар чәчүлек мәйданның хәзер хаҗәте калмагач, ул җиргә башаклы культуралар чәчеп, аннан 3000 центнер иген уңышы җыеп ала башлаганнар (Казан утлары).*

**БАШАКЛЫЛАР** *күпл.* КОЛОСОВЫЕ. Кыяклылар семьялыгыннан орлыклары башакланып урнашкан кыяклы үсемлекләрнең гомуми атамасы; башаклы культуралар, башаклы үсемлекләр. *Барлык төр кыяклылар, --- чәчәк төркеменә карап, башаклыларга (арыш, бодай, арпа) һәм себеркәчлеләргә (солы, тары, сорго) аерыла (Татар энциклопедиясе).*

**БАШАКЛЫ ҮСЕМЛЕКЛӘР** *күпл. к.* **башаклылар**. *Кузаклы, башаклы үсемлекләр яисә күпьеллык үлән чәчсәң, бер елда туфрак паразит суалчаннардан арына (Татарстан яшьләре).*

7. Фонетик вариантлар авыш сызык аша күрсәтелде, төп термин буларак кулланылган атама беренче итеп бирелде:

**НӘРКИС / НӘРКӘС / НӘРГИС** НАРЦИСС. Амараллисчалар семьялыгыннан озын тар яфраклы, хуш исле ак яки сары чәчәкле күпьеллык суганчалы үсемлек; суган гөле. *Кояш каршыдагы кыеклар өстеннән генә сузылып карый, агач башлары талгын гына яна, терраса алдындагы георгиннар, нәркисләр, резедалар да, хәл кергәндәй, иелгән башларын күтәрә төшеп, ачылыбрак киткәннәр --- (Ә. Еники).*

**КЫНДЫРАК / КОНДЫРАК** КОСТЁР. Кыяклылар семьялыгыннан шуышма тамырлы, салам сабаклы, озын тар яфраклы, себеркәчкә тупланган вак чәчәкле күпьеллык үләнчел үсемлек. *Кындырак, айравык, солыча, төлкекойрык, болын саруты... заманында авыл табынының хуш исле чәен алыштырган (М. Рәфыйков).*

8. Кайбер очракларда тигез хокуклы атамалар да авыш сызык аша китерелде:

**БӘКАМ / БӘКАМ АГАЧЫ** ДЕРЕВО САНДАЛОВОЕ, САНДАЛ. Сандалчалар семьялыгыннан гадәттә шикәр камышы, бамбук, пальма һ.б. үсемлекләр тамырының сүлен суырып, паразит булып яши торган, үзагачы эфир майларына бай булган мәңге яшел тропик агач. *Әрем, --- артыш, бәкам, кипарис --- исе тынычлап йоклап китәргә булыша (Сәламәт булыйк!).*

**ХАН / ХАН ҮЛӘНЕ** *диал. к.* **кырлыган**[1]. *Хан үләнендә антиоксидантлар күп – шуның белән ул яман шеш күзәнәкләренә каршы көрәшә (Шәһри Казан).*

9. Лексик-семантик вариантлар (ЛСВ) һәрберсе баш сүз итеп алынды, татар теле сүзлекләрендә шул сүзләрнең мәгънәләрен бирү тәртибендә алар төп атама ахырының өске өлешендә гарәп цифрлары белән күрсәтелде.

**ҖИМЕШЛЕК**[1] ПЕСТИК. Чәчәкнең аналык органы; җимшәнлек. *Бөртекчә – коры җимеш, аның элпәсыман җимешлек тирәлеге орлык кабыгына тоташып үсә, һәм шуңа күрә аны орлыктан аерып алып булмый (Ботаника).*

**ҖИМЕШЛЕК**[2] ФРУКТОВЫЙ САД. Җимеш бакчасы; җимеш агачлары үскән урын. *Аска карася, гаҗәеп матур күренеш: гөлбакча, җимешлек, кәүсәр күле, хур кызлары... (С. Поварисов).*

**КАБЫК**[1] КОРА. Агачның үзагачтан аерылып торган тышкы катлавы; кайры. *Юл өстендә тәгәрмәч астында изелеп, кабыклары суелып беткән ботаклар, агач тамырлары, таяклар очрады --- (Н. Фәттах).*

**КАБЫК**[2] КОРКА. Кайбер яшелчә һәм җиләк-җимешләрнең табигый каты тышчасы. *Кыяр кабыгында минераллар, клетчатка һәм фитохимик матдәләр бар (Шәһри Казан).*

**КАБЫК**[3] ЛУЗГА. Көнбагыш, тары, карабодай һ.б. кебек үсемлек орлыкларын төреп алган тышча. *Янәшәсендә шешә бөкеләре, тәмәке төпчекләре, көнбагыш кабыклары ауный (С. Зыялы).*

10. Шул ук принцип ике яки берничә атама бер үк сүз белән аталганда да сакланды:

**АКБАШ**[1] *диал. к.* **әнис**. *Су буенда акбаш – әнисләр хуш ис тарата (Казан утлары).*

**АКБАШ**[2] *диал. к.* **әнеч**. *Ишегалдында ямь-яшел: әнечтер, акбаштыр – болын инде менә (Р. Газиз).*

**АКБАШ**[3] *диал. к.* **меңьяфрак**.

11. Омонимнар һәрберсе мөстәкыйль сүз итеп алынды һәм якты рим цифрлары белән аерылды:

**ТУЗ** I БЕРЕСТА. Каен кайрысы. *Инде алай да чыгарга теләмәсә, өн авызына учак ягып ыслыйлар. Моның өчен башта мул итеп каен тузы кубарыла, коры-сары җыела (М. Хәсәнов).*

**ТУЗ** II *к.* **куык гөмбә**. *Туздырма тузны, кыздырма кузны (Мәкаль).*

12. ЛСВ төрле тематик төркемгә караган очракларда да бу принцип сакланды:

## I. ҮСЕМЛЕКЛӘР БЕЛӘН БӘЙЛЕ ГОМУМИ ТӨШЕНЧӘЛӘР

**ШЫТЫМ**[1] ВСХОДЫ. Орлык яралгысыннан чыккан үсенте; уҗым. *Авыл халкы беренче тапкыр тигез чәчелгән уҗым шытымнарын күреп таң кала (Т. Нәҗмиев).*

## VIII. ҮСЕМЛЕКЛӘР АНАТОМИЯСЕ, ФИЗИОЛОГИЯСЕ БЕЛӘН БӘЙЛЕ АТАМАЛАР

**ШЫТЫМ**[2] РОСТОК. Үсемлекнең җир өстендә күренгән беренче яшь сабагы яки яфрагы. *Менә чүп арасыннан сиреньнәрнең яшь шытымнары килеп чыкты* --- *(А. Гыйләҗев).*

**ШЫТЫМ**[3] ПРОРОСТОК. Орлык яралгысы бөртүдән башлап үзлегеннән туклануга күчкәнгә кадәрге яшь үсемлек.

13. Үсемлекнең җимеше азык-төлек буларак кулланылган очракта ул түбәндәгечә бирелде:

**АЙВА** АЙВА. Гөлчәчәклеләр семьялыгыннан хуш исле, тәме ачы, алмага яки грушага (армутка) охшаган, каты җимешле мәңге яшел тропик агач; шул агачның җимеше; сәфәрҗәл. *Урамда күркәләр бик күп; саман өйләрнең каршысында җимеш агачлары – зәйтүн, айва үсә (Р. Батулла).*

**ИНҖИР / ИНҖИР АГАЧЫ** ИНЖИР, ФИГА, ФИГОВОЕ ДЕРЕВО, СМОКОВНИЦА. Тутчалар семьялыгыннан киң ябалдашлы, кышын коела торган кытыршы яфраклы, сусыл, татлы җимешле, кипкән тамырлары тәмләткеч итеп кулланыла торган тропик агач; шул агачның җимеше. *Ул, пальмалар, кипарислар, инҗирләргә карый-карый, күреп түгел, исемен ишетеп кенә белгән Таняларның ишегалдына килеп керде (Ф. Җамалетдинова).*

14. Сүзлекнең төп өлешеннән соң русча терминнарның алфавит тәртибендә күрсәткече бирелде. Сүзлек ахырында татар телендә үсемлекләргә бәйләнешле кайбер мәкаль-әйтемнәр, сынамыш һәм ышанулар урын алды.